ЯКЫН КИЛМӘСКӘ!

Белгечләр эт «туй»лары чорында аеруча сак булырга куша

> 2

КЕМ ГАЕПЛЕ?

Татарстанның бер лагеренда өстенә футбол капкасы төшкән 13 яшьлек бала – хастаханәдә

> 3

МАРАТ КӘБИРОВ:

«Илледәге кеше өметләренә тиенә генә башлый. Мин хәзер моны яхшы аңлыйм»

> 4

ТАЛАНТЛАРГА – «ТАНТАНА»

Быелгы театраль «Оскар» нилләр белән истә калыр?

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 44 (29011) | Чәршәмбе | 29 март | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

БҮЛӘКЛЕ ӨМӘ

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Икеайлык башлана

Татарстанда 1 апрельдән чистарту икеайлыгы башлана. Шул ук көнне «ЭкоЯз – 2022» бәйгесенә дә старт биреләчәк. Республикакүләм өмәне 29 апрельдә уткәрәчәкләр. Бу хакта Хөкүмәт йортында узган очрашуда Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков хәбәр итте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Үзеңнең ишегалдыңны җыештырасың һәм бездән бүләк аласың. Чөнки теләге булган һәр кеше «ЭкоЯз» бәйгесендә катнаша ала. Ә бит кар эрегәч, җир өстенә нилләр генә чыкмый, – ди министр.

Җир кардан арынгач, чүп-чарны хуҗалары җыештырырга тиеш. Быелдан министрлык Казан җитәкчелеге белән әнә шулай килешкән. Бу барлык районнарга да кагыла.

– Экологлар да, күзәтчелек органнары да чистарту эшләрен башкарырга әзер. Министрлык хезмәткәрләре бу хакта районнарга да чыгып сөйләшүләр уздырды. Сүз уңаеннан, министрлыктагы 126 инспекторның һәрберсенә 500 кв. км җирнең чисталыгын күзәтергә туры килә, – ди ул. – Икеайлыкта гына түгел, тирә-якның чисталыгын даими рәвештә кайгыртырга кирәк. Әчәр сумы ул, сулар һавамы – барысы да кайгыртуны таләп итә. Без быел да сулыкларга игътибарны киметмибез. Елга, чишмәләр – күз уңында. Авыллардагы су башныларын барлый башладык. Республиканың 14 районында ревизия булды инде. Аларның һәркайсына лицензия бирелә. Ул бар икән, димәк, су сыйфатлы. «Экология» илкүләм проекты кысасында «Иделне сакыктыру» проекты да дәвам итә.

Министр ләм басулары хакында да сөйләде. Без, бер төркем журналистлар, ләм басуын киптерүләрен, канализациядән агып чыккан калдыклардан яндырырга яраклы катнашма ясауларын күреп кайткан идек инде. Бу катнашмалар һаваны пычратмаячак.

Александр Шадриковны Түбән Кама сусаклагычында тик яткан торбалар да борчый. Аларны чыгаруны 2019 елда башлаганнар иде. Быел бу эшне төгәлләсәләр икән.

– Соңгы ике ел эчендә «Уникаль су объектларын саклау» проекты ярдәме белән Татарстандагы өч елганы чистарттык. Болар – Лаеш районының Никольское авылы янындагы Мишә култыгы, Державино авылы куле, Мамадыш районының Нократ елгасының уң култыгы. Быел Мамадыштагы тагын бер елганы – Кама урманнары авылындагы Бөрсетне чистартып бетерәчәкбез. Шушы максатларга 2021–2023 елларга 281 миллион сум акча бирелде. 2025 елда әлеге максатларга 5 елганы савыктыру өчен 170 миллион сум акча тотылачак, – ди министр.

Акча турында сүз чыккач, табигатьне саклауга тотылган калган чыгымнарны да санап китик инде. Александр Шадриков соңгы 5 ел эчендә республикада 850дән артык табигатьне саклау чаралары үткәрелгәнен әйтте. Моның өчен дәүләттән 52,2 млрд сум акча бирелгән. 2022 елда әйләнә-тирәне саклау өчен 15 млрд сум акча тотылган.

– Экологияне кайгыртып, без республикада яшәүче 2,3 миллион кешенең тормыш шартларын яхшыртабыз. Уртак тырышлык белән без табигатькә салынасы 58 млрд сумлык зыянны булдырмый калдык, – ди ул.

Министрдан «ВТ» хәбәрчесе быелгы ташу хакында да сорашты.

– Түбән Кама һәм Куйбышев сусаклагычындагы су биеклеге һәрдаим күзәтү астында. Сусаклагычларда су биеклеге 53 метрга җиту – безнең өчен иң куркүсез. Әмма кайбер районнарда бу куркүсез булганда, халыкны су баса башлый. Димәк, яр буйларында нидер төзәгәндә, су басу куркынычы исәпкә алынмаган. Әлегә сусаклагычларда су биеклеге 49 метрны тәшкил итә. Шушы куркүсез сакларга тырышырга кирәк, – ди министр.

Инде чүплекләргә күчсәк, былтыр тиешсез урында ташланган калдыкларга бәйле 7 мең тәртип бозу очрагы теркәлгән. Былтыр икеайлык кысасында 4574 чүплек табылган. Аның 85 проценты юкка чыгарылган, әмма кайберләрен бетерүне ел буена сузганнар. Министр әйтүенчә, Татарстанда законсыз чүплекләр 10 процентка кимегән.

– Бездә икешәр ел тузып яткан чүп урыннары бар. Казанның Совет районында тәзелеш калдыкларын әле дә юкка чыгарылмаган. Район хакимияте ансат кына котыла. Әлегә җитәрлек финансланмау сәбәпле, чүплекне бетера алмыйбыз, дип җавап бирәләр. Эшләре судка барып җитте. Питрәч районының Богородское авылында да чүп былтырның маеннан бирле ята. Бу бит – район башлыкларының йөзе, – ди министр.

Кыскасы, тиздән кулга тырма, себерке алып, өмәгә чыгар чак җитә. Һәркем үзе яшәгән җирне чүптән арындыра ала. Министр 9 Май бәйрәменә шәһәрләрне чистартып бетерергә дигән максат куйган. Шуңа битараф булмаган һәр кешене өмәгә чакыра.

САН

Узган ел санитар-экологик икеайлык кысасында тиешсез урынга җыелган 4 меңнән артык чүплек бетерелгән. Өмәләрдә 1,5 мең агач утыртылган. Бу эштә 750 меңнән артык кеше катнашкан. Полигоннарга 510 мең куб метр калдык чыгарылган. Күзаллау өчен, бу – 50 мең «КамАЗ» машинасы дигән сүз.

Хәвеф-хәтәрсез узсын

Татарстанда су басу куркынычы кочая. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Гадәттән тыш хәлләр буенча фәнни-тикшеренү институты җитәкчесе Максим Бедило фикеренчә, Татарстаннан тыш, Саратов, Тула, Оренбург, Түбән Новгород, Мәскәү өлкәләрендә, Пермь крае һәм Удмуртиядә шундый ук хәл күзәтелә.

Белгеч әйтүенчә, елгаларда боз катламының калынлыгы төрлечә: кайдадыр – 60, ә кайдадыр 10 сантиметр гына. Шул сәбәпле боз кисәкләренең ярдан аерылу, кешеләр һәм техниканың боз астына төшеп китү куркынычы арта.

Республикада язгы ташу котелгәннән көчләрәк булган очракта 39 муниципалитетта 220 торак пунктка су басу яный. 13,6 мең кеше, 10 социаль объект, 47 автомобиль юлы өлеше, 22 күпер һәм өч заводның табигать казасыннан зыян күрү ихтималы бар, дигән сүз бу.

Сатучылар остарган

Татарстан интернет аша сатучылар эшчәнлеге буенча иң яхшы төбәкләр исемлегенә кергән. Data Insaight агентлыгы төзегән рейтингта республика Россия шәһәрләре арасында – алтынчы, Идел буе федераль округы төбәкләре арасында беренче урынга чыккан.

Агентлык мәгълүматларына караганда, илдә онлайн сәүдә базары, 38 процентка артып, 5,66 триллион сумга җиткән. Лидерлар өчлегенә Мәскәү, Мәскәү өлкәсе һәм Санкт-Петербург кергән.

Республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Татарстан электрон сәүдәгә ярдәм итү программасын кабул иткән төбәкләрнең берсенә әйләнгән. Шушы ярдәм нәтиҗәсендә узган елда интернет аша сатучылар саны ике тапкыр арткан, эшмәкәрләр саны 45423кә җиткән. Алар барлыгы 50,37 миллиард сумлык товар саткан. Россия буенча сатучыларның уртача керемеңнән өч тапкыр зуррак сан бу. Шуңа күрә Татарстан Рәисе ярдәмнең 2025 елга кадәр озайту турында карар кабул иткән.

Урманчылар әзерләнә

Татарстанда «Экология» илкүләм проектының «Урманнарны саклау» федераль проекты кысасында урманнарны яңарту эшләренә әзерләнәләр. Урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров әйтүенчә, ведомство карамагындагы барлык оешмаларда урман хуҗалыгы техникасы һәм җиһазлар әзерләп куелган, агач утырту өчен барлык кирәк-ярак сатып алынган. Быел язның иртә килүе сәбәпле, апрель урталарында ук эшкә керешү күздә тотыла.

Министрлыкның урманнарны яңарту буенча җитәкчесе Тимур Галиев сүзләренә караганда, питомникларда, торф вагы һәм көл сибеп, кар эрүне тизләтү, утырту өчен ботаклар әзерләү, орлыкларны чыныктыру-әзерләү эшләре дә алып барыла.

Исегезгә төшерәбез: быел Татарстанда «Экология» илкүләм проекты буенча барлыгы 3614 гектар мәйданда урманнарны торгызу эшен башкару планлаштырыла. Моның өчен питомникларда 33,95 миллион данә үсенте әзерләп куелган. Шуның 25,5 миллион данәсе – ылыслы агач, 7,8 миллионы – яфраклы агач, 0,65 миллион данәсе – куак үсентеләре.

Равил Кузюров ышандырып әйткәнчә, урманнарны торгызу, ышыклау полосаларын булдыру, табигатьне саклау чараларын оештыру өчен үсентеләр җитәрлек күләмдә әзерләп куелган.

Яңалык

Вакытын карап аласы

Узган ел Россия даруханәләрендә сатылган һәр 100 кап даруның берсенең яраклылык вакыты чыккан булган. Мондый күңелсез очракларны кисәтү өчен, даруханәләргә техник үзгәрешләр кертергә кирәк, дип саный белгечләр. Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы хөкүмәткә бу уңайдан тәкъдимнәрен юллаган.

Алар кабул ителә калса, даруханәләрдә яраклылык вакыты чыккан бер генә дару да сатылмаячак, дип ышандыралар. Ник дигәндә, техник үзгәрешләрдән соң касса аппараты мондый даруларны бөтенләй «сукмаячак». Шул рәвешле дарулар да маркировкалана башлаячак. Белгечләр, яңалык дару бәяләренә берничек тә йогынты ясамас, дип ышандыра. Препаратларның сыйфат ягын кайгыртып эшләнә бу.

«Гадел билге» маркировкалау системасы мәгълүматларына караганда, узган ел Россия даруханәләрендә сатылган һәр 100 кап даруның берсенең яраклылык вакыты чыккан булган. Бу – якынча 80 мең кап дигән сүз.

– Дөрес, ил күләмендәге дару әйләнеше күләме белән чагыштырганда бу әллә ни зур сан да түгел кебек. Узган ел илдәге даруханәләрдә аена уртача 370 миллион кап дару сатылган. Шулай да бу проблемага күз йомарга ярамый. Даруларны да маркировкаларга кирәк. Яраклылык вакыты чыккан дару файдасыз булудан бигрәк, кешеләр сәламәтлегенә дә зыян салырга мөмкин бит, – ди «Гадел билге» маркировкалау системасы белгече Андрей Артамонов.

Бу фикер белән табиблар да килешә. Гомуми практика табибы Фирая Ахунова сүзләренә караганда, яраклылык вакыты чыккан дарулар шундук чүп чиләгенә ыргытылырга тиеш.

– Срогы бер атна, бер ай элек кенә чыккан икән, кулланса була әле, дип уйлаучылар ялгыша. Әйтик, инъекция ясау өчен кулланылучы эремәләрдә яраклылык вакыты чыккач, агулы матдәләр пәйда була. Күзгә сала торган тамчылар белән дә сак булырга кирәк. Яраклылык вакыты чыккач, аның составындагы консервантларның файдасы бетә, анда бактерияләр үрчи башлый, – ди белгеч.

Даруханәдә яраклылык вакыты чыккан дару сатып алган кеше аны кире кайтара аламы?

– Закон нигезендә даруларны кире кайтару тыела. Әмма бу сыйфатлы препаратларга гына кагыла. Даруның яраклылык вакыты чыккан, яки аның төсе, исе, зурлыгы аңлатма язуында язылганнарга туры килми икән, кеше аны даруханәгә кире кайтара ала. Болар бар да «Кулланучылар хокукын яклау турында»гы Закон да күрсәтелгән, – ди юрист Роман Архипов.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Яна ЮРАКОВА, Positive Technologies тикшеренү төркеме аналитигы:

Мошенниклар алдау ысулларын табып кына тора. «Пушкин картасы» да искәрмә булмады. Әлеге картадагы акчаны алу тәкъдиме килеп ирешсә, ризалашмагыз, шәхси мәгълүматыгызны теләсә кемгә тапшырмагыз. Хәзер аеруча сак булырга кирәк.

(«Российская газета»)

РОССИЯДӘ – ГАИЛӘ



	2021 ел	2022 ел
Гаилә коручылар	924 мең	1054 мең
Аерылышучылар	644 мең	683 мең

Росстат мәгълүматлары буенча

Рәхәт яллар!

Язгы каникул чорында шәһәр читендәге 41 лагерьда 5 меңнән артык укучы ял итә. Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, 9 меңнән артыграк бала каникул вакытын 201 мәктәп яны лагеренда уздыра.

Яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков әйтүенчә, әтиләре мобилизацияләнгән малай-кызлар аерым игътибарга алына. Шәһәр яны лагерьларында – 25 һәм мәктәп яны лагерьларында 148 шундый бала ял итә. Шулай ук тормышта авыр хәлдә калган 679 бала лагерьларга юнәлтелгән.

Лагерьларда һәр көн Россия һәм Татарстан флагларын күтәрүдән, гимнны тыңлаудан башлана.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КАПИТАЛИЗМ: ҖИМЕРЕЛӘМЕ, КАЛАМЫ?

Көнбатышта бара торган финанс турбулентлыгы сәяси элиталар, финанс белгечләре, пропагандачылар күңелендә сорау тудыра: вакытлыча түнтәрелешме бу, әллә системаның җимерелүеме? Көнбатыш лидерлары, аеруча Байден, бернинди дә куркыныч юк, вазгыять контрольдә, дигән фикерне сеңдерергә тырышалар. Аларның позициясе бик аңлаешлы, чөнки лидерлар авызыннан чыккан хәвеф тудырырлык бер генә сүз дә, зур паникага сәбәпче булып, барысын да җимерә ала. Процент капиталына корылган хәзерге банклар, депозит иясләренең 25 проценты акчаларын кире сораса, бирерлек акча таба алмаячаклар. Теләсә нинди зур банкны, нинди генә капиталга ия булмасын, коткы таратып, җиңел генә җимереп була. Банкларның төп капиталы – акция дип аталган финанс куыгында. Кертем иясләренә кайтарып бирү өчен, акцияләрен күпләп сата башласалар, куык тишелә һәм капиталдан берни дә калмый. Без шуны күзәтәбез дә инде. Үткән атнада Европа банкларының капиталы язгы кар кебек эреде. Куык тишелмәсен өчен, ФРС һәм Европа Үзәк банкы күпләп акча басалар һәм банкларга өләшәләр. Бу – күп еллар буе кулланылган ысул, ә нәтиҗәсе нульгә калып бара.

Бу язмада без җимерелүнең асылын түгел, аңа мөнәсәбәтне тикшерик. Лидерлар һәм алар тагарагыннан тукланган пропагандистлар «Куркырлык берни дә юк, кризис зур түгел, үтәчәк» дигән фикерне алга сөрә. Аларга каршы лидерлар белән аларның пропагандистлары бар. Бу очракта Россия һәм аның аркадашлары. «Российская газета», мәсәлән, соңгы санында «Эксперты: Банковский кризис в США не сбавляет обороты и может спровоцировать снижение цен на нефть» дигән язма бирде. Мәскәүнең позициясе шулай ук аңлаешлы: Көнбатыш җимерелә, безгә әллә ни зыяны тимәячәк». Көнбатышның авыр хәле аны Украинага ярдәм итүдән туктарга мәҗбүр итәчәк, дигән өмет тә үстерелә.

Кытайның «Глобал Таймс» газетасы (ул материалларының русчага тәрҗемәсен дә бирә) «Капитализм тупланган дивидендларын тотып бетерә, киеренкелек ноктасына җитеп килә» дигән язма бастырды. Аннан бер кызык факт таптым: баксаң, Франция 14 Африка иленең валютасын контрольдә тота, ә алар үз валюта резервларының яртысын Франция казнасына тапшырып баралар икән. Француз туклыгы менә шулай тәэмин ителә. Тик бу туклык ахырына килеп терәлде инде. «Әмма, – ди «Глобал Таймс», – хәзер француз халкы килеп туган вазгыятьтән чыга алмый. АКШ та чыга алмый…» Кыскасы, әлеге юллар авторы «Ватаным Татарстан»да күптән әйтеп килгән фикерне миллион ярымнан артык тираж белән чыгучы төп кытай сәяси газетасы хәзер кабатлый: капитализм тиз генә бетмәс, ләкин яшәп калуына өмет юк. Проблеманың бер җайсыз ягы бар: Кытай да, Россия дә, ягъни барыбыз да бер үк икътисадый яссылыкта көн күрәбез һәм күпләр өметләнгән «кызыл проект»ка әйләнеп кайту безне коткармаячак.

Россиядә

РОССИЯ АШЛЫГЫН ИКЕ ТАПКЫР КЫЙММӘТКӘ САТАЛАР

Россиянең тышкы дөнья белән сәүдәсен киметү, кыенлаштыру, бездә товар кытлыгы булдыру Көнбатышның соңгы бер елдагы сәясәтенең төп нигезенә әверелде. Вашингтон һәм Брюссель бу юлы җиңел уңышка ирешә алмадылар. Бердән, Россия чималына мохтаҗлык зур, аннан оппонентлар үзләре дә тулысынча баш тарта алмый. Эмбарго кертелүгә карамастан, Европада Россия нефть продуктларын файдалану дәвам итә. Дөрес, Россиядән түгел, мотор ягулыгын Африкадан, Азиядән алалар. Мәскәү өченче дөнья илләренә арзанга сата, тегеләре Европага кыйммәткәрәк сатып җибәрәләр. Икенчедән, дус илләр Россия белән араны өзәргә теләмиләр, чөнки бу икътисадый яктан зыянлы. Технологик товарлар белән Россия үзе шулай кылана: Көнбатыш товарларын дус илләр аша кайтарта. Үзеңнекен арзанга сатасың, тегеләрнекен кыйммәткәрәк аласың – төп югалту шунда. Әмма Көнбатышта санкцияләрнең 11 нче пакетын әзерлиләр. Бу юлы камчы арадашчы илләр җилкәсенә төшәргә тиеш. «Пакет» кабул ителгәнче үк, Төркия һәм Казахстан белән сәүдә кыенлашты инде. Санкция исемлегенә кертелгән товарларны безгә үткәрмәскә тырышалар. Арадашчылык керемле булса да, тыелырга туры килә. Дус илләрнең үз товарларын Россиягә керттермәскә тырышу сәясәте дә үткәрелә. АКШ, мәсәлән, үзбәк мамыгына басым ясый, аның төньяк державага сатылуына чик кую белән яный. Үзбәкләр өчен бик зыянлы тыю бу, чөнки, бердән, мамыкка Россиядән башка базар юк, икенчедән, Россия инде мамык белән үзен үзе тәэмин итеп килә, дип зарланалар.

Санкцияләрдән икътисадый зыян аз түгел. Россиягә бурычлы илләр агымдагы бурычларын түли алмыйлар, чөнки халыкара түләүләр системасыннан өзделәр. Бюджетка керергә тиешле дистәләгән миллиард сум керми кала. 2022 елда бары тик 11 миллиард сум бурычны гына кайтарып алып булган. 48,7 миллиард сум түләргә тиеш булганнар. Путин да: «Без долларга кизәнмибез, аны безгә бирмиләр», – дип әйтеп куйды бит.

Санкцияләр ашлык белән сәүдә итүдә дә чагыла. Болай да дөнья базарында ашлыкка бәя төште. Базарлардан өзелү сәбәпле, Россия үз ашлыгын дус илләргә бик арзанга озатырга мәҗбүр. Россиянең Ашлык берлеге президенты Аркадий Злочевский Казахстаннан зарлана. «Казахстан гражданнары Россиядә ашлыкны сатып алалар да элеваторларга пошлинасыз ташыйлар, үзләренеке дип рәсмиләштерәләр», – ди. Шул рәвешле үзләренекенә әйләндергәч, Россия ашлыгын Үзбәкстанга ике тапкыр кыйммәткәрәк саталар икән. Дус илләр белән сәүдәдән килгән зыянның күпмегә төшүе билгесез. Безне бик бай ил булуыбыз гына коткара. Күңелдә бер сорау туа да куя инде: теге иркенлек елларында безне ник бик кысып тоттылар икән?



Илдар Мөхәммәтҗанов

АЛГАНЧЫ ТҮЛИСЕ БАР

Җиде кат үлчәп, бер кат кисәсе. Нәрсәне дисезме? Субсидия күләмен. Хөкүмәт торак-коммуналь хезмәтләр өчен субсидия билгеләү тәртибенә үзгәрешләр керткән. Алга таба айлык керемнәре азрак булган гаиләләргә дәүләттән ярдәм алу да җиңеләячәк. Санап карыйбызмы?

Илдә яшәүчеләрне өч төркемгә бүләргә мөмкин. Беренче төркемгә керүчеләр ташламалардан мөмкин кадәр күбрәк файдаланып калырга тырыша, шуңа күрә алар кемгә һәм нәрсә тиеш икәнен бик яхшы белә. Икенче төркемдәгеләр бу мәсьәләгә битараф, миңа барыбер булмый ул дип, кул гына селтиләр. Ә өченче төркем вәкилләре бу хакта, гомумән дә, берни белми. Шуңа күрә иң элек субсидиянең ни икәнен искә төшерик. Гади сүз белән әйткәндә, бу – дәүләттән ярдәм чарасы. Заманча итеп әйтсәк, «кешбэк». Син акча түлисең дә, дәүләт шуның күпмедер өлешен кире кайтара. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен дә тиеш ул. Дөрес, аз керемле гаиләләргә генә. Аз керемле гаилә яки ялгыз яшәүче ир-ат яки хатын-кыз дип җан башына айлык кереме төбәктәге яшәү минимумыннан (Татарстанда ул быел – 12219 сум) артмаучылар исәпләнә.

Алсу һәм Марат Гайнуллиннар Казанда тора. Алсу кечкенә кызы белән декрет ялында утыра. Олы уллары мәктәптә укый. Бер генә кеше эшләгәнлектән, әлеге гаилә – аз керемлеләр рәтендә.

– Коммуналь хезмәтләр өчен субсидия алырга документларны Дәүләт хезмәтләре порталы аша ярты елга бер тапкыр тапшырам. Матди ярдәм күләме «счет-фактура» бәясенә карап, төрлечә килә. Кышкы айларда ай саен 6 мең сумга якын акча алдым, – ди яшь әни.

Торак-коммуналь хезмәтләргә субсидия алу өчен ил гражданины булып исәпләнү, фатирда «прописка»да тору, ут һәм су өчен түләгәндә бурычларың булмау кебек шартлар бар. Татарстанда коммуналь түләүләргә киткән чыгымнар гаиләнең айлык кеременең 21 (илнең төрле төбәкләрендә әлеге күрсәткеч аерыла. – **Ред.**) һәм аннан да күбрәк процентын алып торган очракта, субсидия билгеләнә. Ил Хөкүмәтендә әнә шул күрсәткечне акча янчыгына турыдан-туры бәйләргә тәкъдим иткәннәр. Ягъни гаиләнең айлык кереме кимрәк булган саен, субсидия билгеләү өчен чикне дә киметергә кирәк, дигәннәр.

– Әлеге чикне илнең Төзелеш һәм ТКХ министрлыгы киңәш-тәкъдимнәреннән чыгып, һәр төбәк үзе билгели алачак, – дигән Россия Дәүләт Думасының Төзелеш һәм ТКХ комитеты җитәкчесе урынбасары Светлана Разворотнева.

Саннарга күчсәк, мәсәлән, гаиләнең айлык кереме 15 мең сумнан артмый икән, әлеге чикне 15 процент (бу очракта коммуналь түләүләр 2,25 мең сумнан артмаска тиеш), айлык керем 20 мең сум булса – 20 процент (ут һәм суга айлык чыгымнар 4 мең сумнан артмаска тиеш) итеп билгеләргә мөмкиннәр.

«Шәһәр икътисады институты» фонды мәгълүматларына караганда, Мәскәүдә субсидия билгеләү өчен коммуналь түләүгә киткән чыгымнар айлык керемнең – 10, Уфада – 13, Мәскәү өлкәсендә 22 проценты дәрәҗәсендә билгеләнгән. Ил күләмендә әлеге күрсәткеч 22 процентка тиң. Төбәкләр аны төшерә ала, тик арттырырга гына ярамый.

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, республикада ташлама-субсидияләр түбәндәге категория гражданнарга бирелә:

- ✓ хезмәт ветераннарына;
- ✓ Татарстан дәүләт бүләкләре белән бүләкләнүчеләргә;
- ✓ реабилитацияләнгән гражданнарга;
- ✓ сәяси репрессияләрдән зыян күрүчеләргә;
- ✓ өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүчеләргә;
- ✓ авыл җирендә эшләүче һәм яшәүчеләргә;
- ✓ инвалидларга;
- ✓ инвалид балалары булган гаиләләргә;
- ✓ техноген һәлакәтләрдән зыян күрүчеләргә;
- ✓ Бөек Ватан сугышы ветераннарына.

Социаль ярдәм чараларына гаризаны Татарстан Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы **(uslugi.tatarstan.ru)** аша тапшырырга мөмкин. Моның өчен гариза тутырырга гына кирәк, барлык кирәкле белешмәләрне социаль яклау органнары үзләре ведомствоара хезмәттәшлек системасы аша алачак.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Кычкырырга түгел, аңлатырга

ГОД ПЕДАГОГА И НАСТАВНИКА 2023 УКЫТУЧЫЛАР ҺӘМ ОСТАЗЛАР ЕЛЫ

Укытучы булырга мәктәптән үк өйрәтә башладылар. Быел республиканың 150 мәктәбендә барлыгы 180 педагогик сыйныф ачылды. Анда 3,5 меңнән артык бала укый. Әлеге укучылар өчен КФУда «Укытучы булу – шәп!» дип аталган I слет оештырылды. Белгечләр моны кадрлар кытлыгын бетерү өчен яхшы чара дип бәяли. Укуын укырлар, тик мәктәпкә әйләнеп кайтырлармы?

Республикада педагогик кадрларга ихтыяҗны (фаразлар) исәпкә алсак, киләсе уку елында 1298 укытучы кирәк. Әйтик, бу уку елында башлангыч сыйныф, математика, физика, химия, рус теле, чит телләр укытучыларына кытлык бар иде.

– Педагогик сыйныфлар ачуны бик хуплыйбыз. Районда инглиз, рус телләре, математика, физика, химия укытучылары җитми. «Авыл укытучысы» программасы буенча өч укытучы кайтты. Алар физика һәм математикадан укыта. Вузларда максатчан программа буенча белем алучы студентларыбыз бар. Өлкән укытучылар күп. Алай да безгә 25–30 педагог кирәк әле. Яшьләр үз теләкләре белән кайтсын иде, – диде слетта катнашучы Сарман методик берләшмәсе җитәкчесе Гөлназ Исмәгыйлева.

Быел Җәлил бистәсе һәм Сарман мәктәпләрендә педагогик сыйныфлар ачканнар. Анда 48 бала шөгыльләнә. Сыйныфлар ике елга исәпләнгән. Киләсе елга башка мәктәпләрдә дә оештырмакчылар.

Сармандагы шундый сыйныфларның берсендә укучы Әдилә Вәлитованың хыялы – укытучы булу:

– Әнием Лилия физика һәм математика фәннәрен укыта. Аңа карап, миндә дә укытучы булу теләге уянды. Мөгаллим дәфтәр тикшерүче, дәрес алып баручы гына түгел, ул – тормышта юл күрсәтүче дә. Әгәр педагоглар безне, заманны аңламаса, укучылар белән укытучылар арасында бәхәс мәңге бетмәячәк.

Тукай районы мәгариф идарәсе башлыгы урынбасары Гүзәлия Хәбетдинова әйтүенчә, районда өч педагогик сыйныф эшли.

– Районда 402 укытучы бар. Быелга укытучылар тупланган. Әмма кадрлар кытлыгы ел саен туып тора. Гадәттә, химия, математика, башлангыч сыйныф укытучылары җитми. Ни өчен дигәндә, районда бала саны ел саен 300гә арта. Халыкның әкренләп шәһәрдән авылга күчүенә бәйле бу, – диде Гүзәлия Хәбетдинова.

Арчадан килгән 8 нче сыйныф укучылары Газиз Латыйпов һәм Дания Хәбибуллина белән дә аралашып алдык.

– Мине мәктәптә эшләү куркытмый. Киләчәктә математика, физика укытучысы буласым килә. Фикерем үзгәрмәс дип уйлыйм, – ди Газиз.

Дания исә үзен тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы буларак сынарга тели. Педагогик сыйныфны тәмамлагач, Арча педагогия көллиятенә укырга барырга җыена.

– Әнием инглиз телен укыта, ике әбием дә – мөгаллимәләр. Мин дә алар сукмагыннан атларга телим. Беләм, замана баласын тыңлату җиңелләрдән түгел. Алар белән бер дулкында булачакмын. Кычкырырга түгел, яхшылап аңлатырга кирәк, – ди Дания.

Слетта катнашучыларга Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин да үз теләкләрен җиткерде.

– Укытучылар җитми. Әмма аңа карамастан, мәктәпләрне педагогларсыз калдырмыйбыз, – диде министр. – Бүгенге чараның төп максаты – яшьләрне укытучы һөнәренә тарту. Мәктәпләрдә 6–8 сыйныф укучылары өчен – профиль алды, 10–11ләрдә профильле сыйныфлар ачылды. Анда шөгыльләнүчеләргә бүгенге чарада педагогик уку йортлары җитәкчеләре, бәйгеләрдә җиңү яулаган укытучылар мастер-класслар күрсәтәчәк.

Министрдан социаль челтәрләрдә актив булган укытучыларга карата мөнәсәбәтне үзгәртү, аларны гаепләүгә юл куймау турында да сорадык.

– Социаль челтәрләрдә укытучыларга гына түгел, башкаларга да эләгә. Анда бер эше дә булмаганнар утыра. Әгәр җәмгыять, әти-әниләр укытучыны гаепле икән, бу юл юньлегә илтми. Укытучылар хөрмәткә, яклауга мохтаҗ. Уңышсызлыкны башка кешедән эзләү – зур хата, – диде министр.

Сәрия МИФТАХОВА

ЯЗГЫ ЭТЛӘШҮ

Борчыган мәсьәлә

Язгы кояш нурлары, җылы һава торышы урамга кешеләрне генә түгел, этләрне дә дәшә. Хәер, монда табигать шартлары гына сәбәпче түгел. Белгечләр бу чорда сукбай этләрдән аеруча сак булырга киңәш итә. Чөнки аларда гормональ үзгәрешләр күзәтелә, шунлыктан хайваннар арасында «эт туйлары», бер-берсенә ау, куышу уеннары башлана. Хуҗасыз этләр, төркемнәргә берләшеп, агрессивка әйләнә.

Әйтик, бу көннәрдә Тукай районының Кече Шилнә авылында ике кешегә эт ташланган. Хайванның беренче корбаны хатын-кыз булса, икенчесе – кыз бала. Бәхеткә, эт корбаннарына зур зыян салырга өлгермәгән. Шулай да, әлеге авылда сукбай этләрнең күп булуын искә алсак, борчылырга җирлек бар. Узган ел әлеге авылдан хайваннарны аулауны сорап, 33 тапкыр мөрәҗәгать иткәннәр. Авыл халкы, алардан куркып, балаларын урамга да чыгармый башлаган.

– Этләрнең барысын да хуҗасыз дип әйтеп булмый. Хуҗасы була торып та, иректә йөрүчеләре күп, – диде шушы авылда яшәүче, исемен күрсәтмәүне сораган ханым. – Җаваплылык һәр кешедә булырга тиештер инде ул. Язын этләр аеруча агрессив кебек күренә миңа. Яннарына якын бармасаң да, барыбер куркыта.

Сукбай этләр проблемасы Казанның төрле бистәләрендә яшәүчеләргә дә тынгылык бирми.

– Күпме генә сөйләсәк тә, әйтсәк тә, нәтиҗәсе юк төсле, – диде Осиново бистәсендә яшәүче Галимә Ибраһимова. – Оныгым Салават Күперендәге лицейга барып укый. Этләр һөҗүм итмәсен дип, аны һәр көн мәктәптән каршы алырга барам. Ике ел элек безнең бистәдә булган вакыйгадан соң (ул чагында мәктәптән кайтучы 11 яшьлек малайга эт һөҗүм итеп, сәламәтлегенә зур зыян салган иде. – **Авт.**) алар бераз кимегән төсле иде, тик бераздан кабат арттылар. Этләр кеше, балалар күп була торган җирләрдә йөри. Тукталышлар, мәктәп, балалар бакчалары, кибет яннары – бөтен җирдә шулар.

Роспотребнадзор идарәсеннән алынган мәгълүматлар буенча, Татарстанда быелның ике аенда медицина учреждениеләренә эт тешләүдән зыян күргән 759 кеше мөрәҗәгать иткән.

Ветеринар Айрат Хөснуллин ышандыруынча, этләр кешеләргә болай гына һөҗүм итми. Хәтта язын да.

– Тамгалы сукбай этләрдә язын күзәтелә торган гормональ үзгәрешләр юк. Бу этләр территория сакламый, ана эт эзләми, үз-үзләрен һәм ана этне кешеләрдән саклау инстинкты да юк. Этләр төркеме куркыныч булып тоелса да, алай ук булмаска мөмкин. Әгәр эт ташланган икән, димәк, кешенең аңа якын баруы яки сумка, таяк белән кизәнүе, тибеп җибәрүе, кычкырган булуы бар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ветеринария идарәсе белгечләре әйтүенчә, тышкы билгеләре буенча гына теге яки бу этнең куркыныч тудыруын аңлау җиңел түгел. «Шулай да урамда йөргән этләр янына якын килмәскә тырышыгыз. Төркем-төркем йөргән этләр үзләрен ышанычлы, өстенрәк тота, кешеләрдән курыкмый. Шуңа күрә төркемләп йөргән этләрдән сакланырга кирәк», – ди белгечләр.

СУКБАЙ ЭТЛӘР КҮРГӘН ОЧРАКТА, КАЯ МӨРӘҖӘГАТЬ ИТӘРГӘ?

Татарстан Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең матбугат хезмәте җитәкчесе Айгөл ҖӘЛӘЛОВА:

– Авылларда сукбай этләр турында җирлек башлыгына әйтергә кирәк. Ул, хайваннарны аулау өчен җаваплы булган оешмага шалтыратып, аларны чакырырга тиеш. Казанда исә сукбай этләрне аулау белән «Зооцентр» җәмгыяте шөгыльләнә. Сукбай этләр турындагы мөрәҗәгатьләрне Башкарма комитетта язмача яки телдән кабул итәләр. Шулай ук «Халык контроле» мәгълүмат системасына да язып җибәрергә мөмкин. Моннан тыш, Торак-коммуналь хуҗалык комитетына (Кремль урамы, 11 нче йорт, gkh.kzn@tatar.ru) электрон вариантта яки язма рәвештә хәбәр итәргә була.

Белгечләр, сукбай этләр генә түгел, хуҗасы якында булмаган хайваннар да куркыныч тудырырга мөмкин, ди.

– Бу чорда хуҗаларыннан башка гына йөргән этләр чыннан да куркыныч, – ди үзе дә эт тотучы Оксана Дмитриева. – Без бит беребез дә этне өйдә нәрсәгә өйрәтүләрен белмибез. Бәлки, ул кешеләргә ташланырга өйрәтелгәндер? Бәлки, аны кыйнап торганнардыр яки бәйдә булгандыр? Болар барысы да хайваннарны кешеләргә карата агрессив итә. Мондый этләр ялгыз гына да йөрергә, сукбай этләр төркеменә дә килеп кушылырга мөмкин. Шуңа күрә аларны теләсә кайда очратырга була. Агрессив этне исә электр шокеры яки һавага ис тарата торган баллон сиптереп куркытырга мөмкин. Алар гадәти булмаган тавышлардан шүрли.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КҮҢЕЛСЕЗ ФУТБОЛ

Татарстанның бер лагеренда 13 яшьлек үсмер өстенә футбол капкасы төшкән. Бала – хастаханәдә. Шуклыкмы, игътибарсызлыкмы – хәзер әлеге хәлгә кем гаепле икәнен ачыклыйлар.

minsport.tatarstan.ru

Аяныч хәл 27 мартта «Волга» яшьләр үзәге базасында була. Татарстанның Яшьләр эшләре министрлыгы матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, үзәктә җиде көнлек «Мәрхәмәтле футбол» сменасы бара. Аны «Балалар хыялы» фонды оештырган. Әлеге смена 10–14 яшьлек яшүсмерләр өчен. Яшүсмерләрнең күпчелеге – исәптә торучы яисә социаль яктан имин булмаган яки катлаулы хәлдә калган гаиләләрдә тәрбияләнүчеләр, ди.

Министрлык аңлатмасыннан күренгәнчә, турнир нигезләмәсе кысасында, футбол буенча барлык ярышлар да спорт комплексының ябык бинасында, җылы, җиһазландырылган залда оештырыла. Мондый карарны оештыручылар һава торышына бәйле рәвештә кабул иткән, чөнки урамдагы футбол мәйданы әлегә турнирлар үткәрү өчен тиешле дәрәҗәдә әзер түгел.

Әлки районының бер мәктәбе тренеры исә башкача хәл иткән. Көн тәртибендә каралган йокы сәгате вакытында укучылары белән футбол кырына чыккан. База администрациясе рөхсәтеннән башка, яшүсмерләр футбол кыры чикләреннән уен кыры үзәгенә күнегүләр өчен каралган капканы алып чыккан. Моны видеокүзәтү камераларыннан алынган язмалардан күрергә мөмкин. Сикерү, шаяру, капкада тартылулар нәтиҗәсендә, әлеге конструкция әйләнеп каплана һәм бер яшүсмер өстенә төшә.

Зыян күргән 13 яшьлек малай – Әлки районы Базарлы Матак авылыннан. Шушы хәлдән соң, аны авыр хәлдә башкаланың Балалар клиник хастаханәсенә озатканнар. Малайны хирург, травматолог, яңак-йөз хирургы, ортопед тикшергән һәм компьютер томографиясе ясалган. Хәлен хәзер тотрыклы дип бәялиләр.

Татарстан буенча Тикшерү идарәсе матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, әлеге хәлдән соң «Куркынычсызлык таләпләренә җавап бирми торган гамәлләр башкару яисә хезмәт күрсәтү» маддәсе (Җинаять кодексының 238 нче маддәсе) буенча җинаять эше ачканнар.

Бер караганда, бу вакыйганы тиктормас балаларның шуклыгы дип тә карарга мөмкин. Икенче яктан, укытучы йокы сәгатен күнекмәләр өчен файдаланырга тиешме икән соң? Югыйсә яшь спортчыларга куркынычсызлык кагыйдәләре турында бер генә аңлатмаганнардыр. Гаеп һәрвакыттагыча атта да, тәртәдә дә.

Башкаланың «Юниор» һәвәскәр футбол командасы җитәкчесе Ильяс Баһауов фикеренчә, мондый хәлләрдән барысы да зыян күрә.

– Казанда да мондый очрак булганы бар. Парк исемен әйтеп тормыйм. Анда да футбол уйнау өчен мәйданчыклар каралган. Мини-футбол өчен 8дән артык капка бар иде. Иде... Футбол уйнарга яратучылар өчен Казанда берданбер шундый ачык урын! Берничә ел элек 17 яшьлек кыз, шул капкаларның берсенә асылынып, аны үз өстенә аударды. Борыны сынды бугай аның. Әти-әнисе парк хуҗасын судка бирде. Янәсе, капкалар беркетелмәгән, шуңа шундый хәл. Ләкин никтер 17 яшьлек кыз капкаларның беркетелмәгәнен аңлый алмаган. Бер тиеп карасаң да, аңлашыла инде ул. Капка асылыныр өчен куелмаган! Шул хәлдән соң бу мәйданчыктан капкаларны алып куйдылар. Хәзер инде бирегә футбол уйнарга килүчеләр дә кимеде, чөнки капкасыз уйнау кызык түгел. Бер уйланылмаган адым аркасында күпме кеше зыян күрде. Бу кыз үзе дә! «Волга»дагы очракта да шулай булгандыр дип уйлыйм. Капка ауган икән, димәк, ул беркетелмәгән. Зыян күргән гаиләне дә аңлап була, ләкин алар да менә нәрсәне аңласын иде: капкаларны беркетмәүнең сәбәбе – футбол командалары үзләренең тренировкалары вакытында аларны төрле форматта һәм төрле урында куллануы. Ягъни алар аны яткырырга да, бер-берсенә якынрак китерергә дә мөмкин. Монда күнекмәләрнең үзенчәлегенә карарга кирәк. Гомумән, чын профессиональ командалар базасында да капкалар беркетелмәгән. Аерма шунда: капкага берәү дә асылынмый. 13 яшьлекләр дә, 17 яшьлекләр дә уйлап эш итәргә тиеш, – ди һәвәскәр футболчы.

2 бала анасы Венера Шакирова да кечкенә спортчы тәрбияли. Улы башкаладагы спорт мәктәпләренең берсендә футбол белән шөгыльләнә. «Волга»дагы хәл аны да уйланырга мәҗбүр иткән.

– Каникул саен балалар тренерлары белән ял лагерена барырга тырыша. Хәзер дә улым лагерьда. Лаеш районында чыккан хәлне ишеткәч, йөрәк жу итте инде, әлбәттә. Лагерьдагы гадәти сменалардан аермалы буларак, спорт сменасында шартлар «корырак». Балалар иртә-кич спорт белән шөгыльләнә, лагерь тормышында катнашмыйлар да диярлек. Безнең тренер, мәсәлән, балаларның кесә телефоннарын да, әти-әниләргә шалтыратып алу өчен, көненә бер-ике сәгатькә генә бирә. Аңлашыла инде, бу дисциплина өчен кирәк. Спортчы булырга теләгән балада чыдамлык та, җитдилек тә, мөстәкыйльлек тә булырга тиеш, – дип уйлый Венера Шакирова. – Ә менә ялның сыйфаты һәм балаларның куркынычсызлыгы өчен лагерь җитәкчелеге җаваплы. Мәсәлән, безнең улыбызның бер атналык ялы 8 мең сумга төшә. Эшкә бармак аша гына карарлык аз акча түгел инде бу. Әти-әниләрне койманың теге ягына кертмиләр бит, шуңа күрә без андагы шартларны фотосурәтләрдән күреп кенә беләбез.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

НИШЛӘРГӘ?

Балаларның егылу, бәрелүләре күбрәк гематома чыгу, буыннар тартылу, сынуларга китерә. Сүз уңаеннан, малайларда, кызлар белән чагыштырганда, урам травматизмы 1,9 тапкыр күбрәк очрый. Аяныч нәтиҗәләрне киметү өчен, зыян күрүчегә шунда ук беренче ярдәм күрсәтергә кирәк. Хастаханә вәкилләре килеп җиткәнче, билгеле.

➤**Тынычлык.** Җәрәхәт алуга, баланы яткырырга, авырткан урынга басым ясауны туктатырга кирәк. Аяк-кулларга гипс, махсус бәйләвеч салу мөмкин.

➤**Салкын.** Сөлгегә төрелгән боз, махсус химик пакет, суыта торган спрей – кул астында әнә шулар булса яхшы. Салкын шешне дә, сызлауны да киметә.

➤**Басым.** Җәрәхәтләнгән урынны бинт белән урарга кирәк. Әмма бик тыгыз итеп түгел. Бинтлау эше зарарланган урыннан 3–4 см түбәнрәк, астан өскә таба башкарылырга тиеш.

Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясенә кандидатлар

ҖЫР УЛ – ХИСНЕҢ БАЛКЫШЫ

Наил Касыймов. Бу исем үзе үк шигырь, җыр кебек яңгырый. «Авылым тавышлары», «Кайтуыңны сагынырмын», «Соңлама!», «Су буенда учак яна», «Туй күлмәге», «Биик әйдә!», «Арча чикләре», «Тыңлар идем тавышыңны», «Гүзәл җирем», «Соңгы звонок», «Әнкәм сүзе» җырларын кем генә белми, җырчыларга кушылып, кем җырламый яки үзалдына көйләп йөрми икән?!



Наил Касыймов беренче тапкыр әнисе Фәүзия апага багышлап язылган «Ак яулыклы әнием» дигән җырдан соң (көй авторы – Луиза Батыр-Болгари) танылa. Искиткеч моңлы җыр, исегездәдер: «Ак төсләрне әллә күп сөйгәнгә – чәчләрең дә бүген ак синең. Күңел күгемдә син – якты кояш, ак яулыклы әнием минем».

– Бездә бит хатын-кызлар ак яулыкны олыгайгач кына бәйләргә гадәтләнгән, ә мин әниемне кечкенә чактан ук ак яулыклы итеп кенә беләм. Ак яулык бит ул – татар халкының традициясе, символы, чисталыкка өйрәткән сафлык билгесе, – ди Наил абый.

Аның шулкадәр нечкә күңелле, шигъри җанлы булуы, бер карасаң, гаҗәп тә түгел – олы әдипләребез туып-үскән Арча районы Ашытбаш авылы егете ул. Кечкенә чагында әнисенең туган авылы – Кырлай белән тоташкан Иябаш авылына әбиләренә кунакка барганда, Тукай йөргән сукмаклардан йөргән, Тукай коенган инештә су коенып үскән. «Бәлки, шул инешнең суы бераз сеңеп калгандыр, шигырь язу теләге шул чакта уянмады микән, дип тә уйлап куям», – ди үзе. Мәктәптә укыганда ук инде шигырьләре «Ялкын» журналында, «Яшь ленинчы» газетасында басылган шагыйрь: «Алтмышка җиткәч кенә шигырь яза башлап, үзеңне шагыйрьгә санау дөрес хәл түгел, теләсә нинди сәләт тумыштан килә һәм бала вакытта, яшь чакта ук күңелдән бәреп чыга», – дигән фикердә. Кырлай мәктәбендә югары сыйныфларда укып йөргәндә мәктәпкә килгән күренекле әдипләр иҗатта киләчәге шактый өметле шәйләнгән үсмер Наилне Казан дәүләт университетының филология факультетында укырга өндәсәләр, чакырсалар да, ул: «Төзүче булам!» – дип, Казан төзүче-инженерлар институтына барып кергән.

Аннан яшь белгечнең гомер юлы бик бай эчтәлектә дәвам иткән. Тормыш дулкыннары әле бер тарафка юллаган, әле икенче тармакка юнәлткән: төрле төзелеш һәм сәүдә оешмаларында өлкән инженер, директор, Татарстан дәүләт телестудиясендә редактор, өлкән редактор, Казан шәһәр хакимиятенең мәдәният идарәсендә идарә башлыгының беренче урынбасары, аннан башкала хакимиятенең юллар төзү идарәсендә идарә башлыгы урынбасары, Татарстан Мәдәният министрлыгында бүлек мөдире…

Шул елларда Чирмешән районы Керкәле авылы кызы Гөлсинә белән гаилә кору, улы Айдар туу…

Һәм, кайда гына эшләсә дә, иҗат, иҗат, иҗат… Шигырьләр, җырлар…

Мин аннан: «Нәрсә ул җыр?» – дип тә сорадым. Бу сорау аның үзен дә шактый бимазалаган икән:

– Нәрсә ул җыр?.. Моңа һәркем үзенчә җавап бирә. Мин дә бу сорауга озак кына җавап эзләдем һәм таптым дип беләм. Төрле төсләр тупланышы салават күперен хасил итә. Ә хисләр тупланышы җыр барлыкка китерә. Кеше, хисен гади сүз белән генә аңлатып бетерә алмаганда, кулына каләм ала һәм шигырь яза. Халәтен шигырь белән аңлата. Шул шигырьне укып тәэсирләнеп, композитор көй яза. Җырчы шушы шигырьдән, көйдән илһамланып, сәхнәдән аны җыр итеп халыкка җиткерә. Ә халык ул җырны тыңлап хисләнә, алкышларга күмә. Шулай итеп, башта бер кешедә туган хис үскәннән-үсә, тулылана. Шагыйрь сүзләренә композитор, җырчы, тамашачы үзенең хисен өсти һәм ул хис, зураеп-балкып, бөтен дөньяга тарала. Шуңа күрә, «Җыр нәрсә ул?» – дигән сорауга мин кыска гына итеп: «Җыр ул – хиснең балкышы!» – дип җавап бирәм.

Сүзгә сыймый хис дулкыны,
Сүз ул – хиснең яртысы.
Җырга ия хис ялкыны,
Җыр ул – хиснең балкышы!

Ул иҗат иткән җырларның һәрберсе диярлек халык күңелен яулап ала. Моның хикмәте нәрсәдә? Автор болай аңлата:

– Мин шигырьләремә бик таләпчән, кабат-кабат укып төзәткәннән соң гына әдәбият сөючеләргә тәкъдим итәм.

Җырлап торган, уйга салган, тирән фәлсәфи шигырьләре, җырлары белән халык күңеленә кергән, танылган шагыйрь 1993 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Төрле елларда иҗат ителгән җырларын, шигырьләрен «Күңелем каршында тезләнде…», «Күңелем кояшы», «Су буенда учак яна», «Тыңлар идем тавышыңны…» дигән китапларга туплап чыгарган.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлегенең Һади Такташ исемендәге премиясе лауреаты Наил Касыймов хәзер лаеклы ялда. «Зур чараларда, радио-телевидениедә күренмисез, ни хәлләрдә яшәп ятасыз?» – дигән сорауга шагыйрь: «Мин, гадәттәгечә, тыныч кына иҗат итеп яшәүдә, – дип җавап бирде. – Гомергә тыйнак булдым. Сибгат абый Хәким миңа: «Тарихның җиз иләгендә иләнеп, язган бер генә җөмләң исән калса да, син – бәхетле иҗатчы», – дигән иде. Иҗатыңның киләчәккә баруы саннан түгел, сыйфаттан тора, дип әйтергә теләде ул. Мин һәрвакыт сыйфатка омтылып иҗат итәм. Сан артыннан кумыйм. Аллага шөкер, моннан 30–40 ел элек язылган җырларымның күбесен җырчылар әле дә булса бик теләп башкаралар. Ул җырларны хәзер классик җырлар дип тә атарга була торгандыр. Үз эшеңнең уңай нәтиҗәсен күрүдән дә зур бәхет юк. Бу яктан мин – бик бәхетле кеше!» Без аңа ышанабыз һәм киләчәктә дә шундый матур иҗат, уңышлар телибез.

Назилә САФИУЛЛИНА

Туган җирендә зурласыннар

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Татарстанның Буа районы Яңа Чәчкап авылы мәктәбендә күренекле шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Әхмәт Рәшит исемендәге «Кояшлы ил» дип аталган фәнни-гамәли конференция ел саен аның туган көненә туры китереп, мартның соңгы ункөнлегендә үткәрелә. Быел бу чара җиденче тапкыр оештырылды. Анда катнашу – минем өчен һәрвакыт зур вакыйга.

Быелгысына чакыру алгач исә, сөенеч белән бергә күңелдә борчылу да кузгалып куйды. Моңарчы гөрләп торган, йөз елга якын тарихы булган, бик күп күренекле затларны (шул исәптән Әхмәт Рәшитне дә) олы тормыш юлына чыгарган урта мәктәп юк хәзер. Бу уку елын ул тугызъеллык, ягъни төп гомуми белем бирү мәктәбе булып башлап җибәрде. Директоры Рөстәм Бикмуллин әйтүенчә, балалар саны елдан-ел кими, хәзерге көндә 36 укучыга 15 укытучы белем бирә икән. «Шуңа карамастан, мәктәп үз тормышы белән яши, төрле түгәрәкләр эшләп тора, – дип сөйләде ул. – Авылда Әхмәт абыйның бюстын булдыру, мәктәпкә аның исемен бирү турында уйланабыз. Бу конференцияне дә, Ульян өлкәсе, Чувашия мәктәпләрен дә чакырып, төбәкара дәрәҗәдә оештырырга теләгебез бар».

Фәнни-гамәли конференция хәзергә республика күләмендә уза. Быел, мәсәлән, Апас, Кайбыч, Тәтеш, Кама Тамагы, Зеленодольск районнары мәктәпләреннән килгән укучылар да, күркәм чыгышлар ясап, призлы урыннарга лаек булды. Конференция эше дүрт юнәлештә барды. «Язмышым – шигырьләремдә» һәм «Тел күрке – сүз» дип аталган секцияләрдә балалар Әхмәт Рәшит шигырьләрен, әдәби әсәрләрдән өзекләрне сәнгатьле укуда ярышты. Россия күләмендә Укытучылар һәм остазлар елы, Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы булу да оештыручылар игътибарыннан читтә калмаган. «Язучылар иҗатында – туган илгә мәхәббәт», «Сәнгатьтә – укытучы образы» секцияләрендә укучылар чын мәгънәсендә фәнни эзләнүләргә нигезләнгән хезмәтләрен яклады. Эчтәлеген сөйләп чыгарга гына түгел, авторларга жюриның катлаулы сорауларына да җавап бирергә туры килде. Кыен хәлдә калмас өчен, фәнни доклад әзерләгәндә нәрсәләргә игътибар итәргә соң? Бу уңайдан Татарстан китап нәшриятының Балалар, яшүсмерләр һәм махсус проектлар редакциясе мөдире Айсылу Галиева укучыларга да, укытучыларга да файдалы киңәшләр бирде.

Исән чагында Әхмәт абый очрашуларга үзе дә кайта, шигырьләрен укый, балалар белән аралаша иде. Кызганыч ки, соңгы 1–2 елда аның бәйрәме үзеннән башка гына уза. Тик Яңа Чәчкап мәктәбе коллективы, Әхмәт Рәшит исеменә бәйле чара уздыруны күркәм традициягә әйләндереп, шагыйрьне оныттырмый, авылдашларының аны олылавын, иҗатын яратуларын исбатлап тора. Ә ник олыламаска ди әле?! Күптәннән халыкныкы булып киткән «Беренче мәхәббәт», «Зәңгәр күлмәк» җырларының сүзләрен язган өчен генә дә түгел! Рәшитов Әхмәт Әхәт улы – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, атказанган сәнгать эшлеклесе, унике поэма һәм меңнән артык шигырь авторы, Гаяз Исхакый исемендәге дәүләт бүләге лауреаты да. Әгәр артык тыйнаклыгы да комачауламаган булса, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Шәмсия Җиһангирова әйтмешли, аның иҗаты Габдулла Тукай премиясенә үк лаек иде.

Шәмсия ханым исә юкка гына әйтмәс, чөнки «Татарстан радиосы»нда баш мөхәррир Әхмәт Рәшит кул астында озак еллар эшләү насыйп булган аңа. Шуңа күрә биографиясен дә яхшы белә. «Тормышымда бик зур роль уйнаган кеше», – дип, җылы хисләр белән искә алды ул. Татарстан китап нәшриятында эшләп йөргән җиреннән радиога чакырып китергән икән аны Әхмәт абый. «Атна саен эфирга чыгарган тапшыруларымның «Хәерле иртә» дип аталганы тиз арада популяр булып китте һәм 22 ел буе барды. Яңа килгән кеше дип кыерсытырга теләгәннәргә ирек куймыйча, тынычлап эшләргә, иҗат итәргә мөмкинлек биргәне өчен Әхмәт абыйга бик рәхмәтлемен», – диде Шәмсия Җиһангирова. «Читтә күпме генә хөрмәтләсәләр дә, үз туган ягында кадереңне белмәсәләр, иҗат итүнең әллә ни әһәмияте дә булмас иде», – дип, шагыйрьне зурлаган чәчкаплыларга соклануын да белдерде ул.

Якташыбыз – әле яңарак кына Муса Җәлил исемендәге премиягә лаек булган шагыйрь Рифат Сәлах та рәхмәтле күрше абыйсына. Әхмәт Рәшитне үзенә үрнәк итеп куя, остазы, хәер-фатиха бирүчесе дип саный ул. 2005 елда чыккан беренче китабына кереш сүзне дә Әхмәт абый язган булган.

Бу конференциянең мәктәпләр арасында шулкадәр популяр булуы, катнашырга теләүчеләрнең елдан-ел арта баруы куандыра. Быел, мәсәлән, 130 гариза кергән, шулардан 119 бала үзен сынап карады. Бәйгедә катнашкан эшләрне районыбызның Мәгариф идарәсе вәкилләре, тәҗрибәле укытучылар, танылган шагыйрьләр, журналистлар, вуз галимнәреннән торган жюри бәяләде. I–III урыннар алучыларга 105 дипломны – Татарстан Язучылар берлеге, 14ен Казан дәүләт аграр университеты тапшырды. Балаларны бәйгегә әзерләгән укытучылар исә Язучылар берлегенең Рәхмәт хатларына лаек булды.

Игътибар иткәнсездер: язмамда кайткан кунакларның, жюри әгъзаларының бик күбесенең, хәтта аеруча сәләтле балаларның да, укытучыларының да исемнәрен атамадым. Махсус. Фамилия санап ялыктырасым килмәде. Тик конференциянең шушылай зәвыклы, эчтәлекле узуына үз өлешләрен керткән Салих Шәрәфетдинов, Марат Хисамиев, Сәйдәш Мусин, Нәфигулла Исмәгыйлев, Данир Гыймадов, Нияз Заһретдинов, Ильяс Гыймадов, Разыйф Хисамов исемнәрен язмый булмый инде. Ярдәм итәргә әзер торучы иганәчеләр алар. Күпме генә мактасак та, бу чараның матди ягын мәктәп үзе генә күтәрә алмас иде. Шушы матур бәйрәмдә катнашкан барыбыз исеменнән дә зур рәхмәт бу егетләргә.

Фәния ФӘИЗОВА

Автор фотосы

«Ватаным Татарстан»ның махсус бүләкләре тантаналы ачылышта якташ абыйларының шигырьләрен сәнгатьле итеп укыган чәчкаплыларга әләкте.

КОНТРАКТ БУЕНЧА ХӘРБИ ХЕЗМӘТ

РФ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ БЕЛӘН КОНТРАКТ ТӨЗЕГӘЧ, БЕР ТАПКЫР ТҮЛӘНЕЛӘ:

195 000 сум

Махсус хәрби операциядә катнашкан өчен өстәмә түләүләр каралган

Хәрби комиссариатка мөрәҗәгать итү өчен:

8 (843) 221-44-52



Авыл язмалары

Халәт

Кеше хәтере кыска. Дөньядагы иң әһәмиятле вакыйгаларны да, тарих тәгәрмәчен борып җибәрерлек шәхесләрне дә тиз оныта. Вакыйгаларны бераз хәтерләсә дә, нечкәлекләрен белми башлый, шәхесләрен исеннән чыгарып җибәрә, төрле карашлар, фикерләр арасында буталып, чынбарлыктан читләшә төшә, ахыр чиктә бөтенләй адашып кала. Күп очракта шулай. Ләкин бернинди дөньякүләм әһәмияте булмаган хәлләр дә кайвакыт гомер буена онытылмый саклана, тормышыңның төрле вакыйгаларына яңа төсмер өстәп, хәтергә ияреп йөри. Менә шундый хәлләрнең берсе турында сөйләргә телим.

Илле яшьлек бер күршебез фани дөньядан китеп барды. Бик нык аралашып, дус булып, шатлык-кайгыларны бергә кичеп йөргән кешем түгел инде. Очрашканда исәнлек-саулык сорашып, һава торышын сөйләшкәләп, дөнья хәлләрен чәйнәшеп алган чаклар бар иде, әлбәттә. Үзара ярдәмләшкән вакытлар да булгалады. Ул чакларда күрше белән күрше аралашып яши торган иде, эшен дә бергә эшли, табын да уртак була. Шулай гомер иткәч, бик чит-ят адәм дә түгел иде инде ул. Тик мин ни өчендер еламадым. Хәтта артык кайгырмадым да бугай. Аның үлемен гадәти бер хәл, табигый күренеш кебек кабул иттем. Хәтта күзләрен чылаткан кешеләргә карап, бераз гаҗәпләндем дә бугай әле. Ник шулай җебеп торырга инде, янәсе, яше җиткән, ашыйсын ашаган, яшисен яшәгән. Вакытың килеп җиткәч, әҗәлдән беркая да качып булмый. Дөнья шулай яратылган, табигать шундый. Әлбәттә, алтмыш-җитмешләргә җитсә, бигрәк әйбәт булыр иде дә. Тик нишлисең инде?! Аның каравы, кайбер бабайлар кебек бөкрәеп, җәй көне дә бүрек киеп йөрисе түгел... Кыскасы, мин аның әҗәленә артык кайгырмадым.

Беренчедән, ул вакытта миңа унсигез яшь иде. Унсигез яшьтә хәтта утыздан узганнар да бабай булып күренә. Минем бер абзыйга карап сокланып торганым әле дә хәтердә: «Карале, үзе кырыкка җитеп килә, ә үзе егетләр шикелле!» Шушы күренеш үзе генә дә илле яшьлекләргә карашның нindирәк булганын күрсәтәдер инде.

Икенчедән... Менә монысын ничегрәк аңлатып карыйм икән... Безнең нәселдә хатын-кызлар озак яшәде инде ул. Матур итеп яшәделәр дә, матур итеп, кеше җәфаламый гына үлеп киттеләр. Берсенең дә урын өстендә озак вакытлар буена интегеп авырып ятканы булмады бугай. Ә ирләр гел кыска гомерле. Ике бабам да утызлар тирәсендә үлгән, аларның туганнары да шул чамадан артмаганнар. Хәзер аңлыйм инде, боларның барысына да сугыш сәбәпче булган. Кайсы Герман сугышында, кайсы Гражданнар сугышында, кайсы фин кыйралышында... Ә якын бабайлар – Бөек Ватан сугышында. Хәтта дары исе иснәмәгән үз әтием дә утызга да җитмичә китеп барган. Менә шулай булгач, илле яшь миңа бик зур булып күренгәндер инде.

Әле менә тагын бер күршемне җирләдек. Ул да илле яшьтә иде. Бергә уйнап үскән малайлар инде без. Тик үсеп җиткәч, бик аралашмадык. Икебез дә читкә чыгып киттек тә озак еллар буена күрешмәдек, хатлар, соңрак «смс»лар язу түгел, хәтта ым да кагышмадык. Кыскасы, бер-беребезнең дөньяда барлыгын да белмичә яшәдек. Үлеп китмәсә, мин аны мәңге исемә төшерәсе адәм түгел идем.

Ә үлеме барысын да искә төшерде. Бот буедай малай чакларны да, мәктәп елларын да, үсмер вакытларны да, егет чакларны да. Балачак һәм яшьлек елларын тулы бер бөтен дөнья итеп күз алдына бастырды. И бәхетле булганбыз икән без ул заманнарда! И шулкадәр әйбәт булганбыз икән... Балачак дусларының бер-берсеннән ераклашуы да, бәлки, әнә шул бәхеттән, әйбәтлектән бераз ерагаю булгандыр.

Теге вакытта дөньядан киткән күршемне дә искә төшердем. Һәм еладым. Икесе өчен дә. Илледә кеше бигрәк яшь була бит әле ул. Өметләренә тиенә генә башлый. Мин хәзер моны бик яхшы аңлыйм, чөнки үзем дә – илләне узган адәм.

Марат КӘБИРОВ

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ТАТАРЧА «ОСКАР»:

«ТАНТАНА – 2023» НИНДИ ВАКЫЙГАЛАРЫ БЕЛӘН ИСТӘ КАЛЫР?

Нәтиҗә

Кызыл келәмнән узган актер-актрисалар, остаз һәм аның укучысының җиңүе, 69 спектакль һәм нибары 17 җиңүче. 27 март – Халыкара театр көнендә Әлмәттә «Тантана» театр премиясенең чираттагысы узды.

Рәиссез премия

2022 елдан «Тантана» премиясе күчмә форматта уздырыла башлады. Моңа кадәр Камал театры сәхнәсеннән төшмәгән премия узган ел – Чаллыда, быел Әлмәттә үтте. Күчмә формат башкаладан читтә урнашкан театрлар өчен күтәп алынган вакыйга һәм узган елның төп яңалыгы иде. Ә быелгы премиянең төп яңалыгы – экспертлар советының рәиссез калуы.

– Башка елларда рәислекне мәдәният министры Ирада Әюпова үзе башкара иде, быел исә бу вазыйфаны миңа тәкъдим иттеләр. Ләкин премиядә Камал театры катнашкач, баш тарттым. Хәзер ике рәистәшебез бар. Берсе – Россиянең Театр әһелләре берлеге рәисе урынбасары Дмитрий Мозговой, икенчесе – Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, – дигән иде «Тантана»га багышланган матбугат очрашуында республиканың Театр әһелләре берлеге рәисе Фәрит Бикчәнтәев.

Шулай итеп, экспертларга барлыгы 69 спектакль карап, 17 җиңүчене билгеләргә туры килгән. Инде тантананың үзенә күчик.

«Вообще, батып үлүчеләре дә булган әле...»

Әлмәт театры сәхнәсендә узган «Тантана»ны тантаналы төстә шушы ук театрның «Ул әле өйләнмәгән иде» спектаклендәге ике кызчык-«фәрештә» ачып җибәрде. Аларга кыска һәм оста итеп, премиянең тарихын сөйләү вазыйфасы йөкләнгән иде.

«Еракта-еракта, Җир шарының иң якты бер җирендә яшәгән, ди, булган, ди театрлар. Алар бер-берсен уздыра-уздыра эшләгән, берсеннән-берсе зәвыклы спектакльләр чыгарган. Еллар узган саен, алар бер-берсенә тартылганнар һәм бер агымда иҗат иткәннәр. Но бервакыт что-то не то була башлаган. Шунда, алар бөтен көчләренә эшләсен өчен, түрәләр дәрәҗәле премия уйлап тапкан. Һәм аны «Тантана» дип атаганнар. Һәм шунда башланган инде хәлләр... Бер агымда йөзә торган театрлар аркылыга, буйга, агымга каршы йөзә башлаган. Вообще, батып үлүчеләр дә булган әле... Ә «иңиң»нәре бүгенгә кадәр килеп җиткән».

«Татар-информ»/ Салават Камалетдинов

Айдар Җаббаров куйган «Көл» – кече формадагы иң яхшы спектакль дип табылды.

Кыска да, оста да, әйеме? Уен-көлке, шаяруларга бай була торган премиянең быелгысы да шундыйрак рухта башланды. Шуннан исә сүзне Әлмәт районы башлыгы Тимур Нагумановка тапшырдылар. «Бер кечкә булса да Әлмәтне Татарстанның театраль башкаласы иткәнегез өчен бик зур рәхмәт!» – диде ул.

Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова исә сүзен «Безнең тормыш – үзе театр», – дип башлады. Республиканың театрларга бай булуын һәм, гомумән, Россиянең башка төбәкләре арасында аерылып торуын да искәртте. Билгеле, кабул итүче якка рәхмәт сүзләре дә ирештерелде. «Кадерле театр әһелләре, сезгә мин ирекле мохит һәм чиксез мөмкинлекләр телим!» – диде ул.

Яшьләрдә дә бар

Быелгы театраль «Оскар»да спектакльләрдән бигрәк, актер һәм актрисаларга игътибар зур булды. Шунысы да сөендерә: быелгы җиңүчеләр арасында яшьләр күп. Әйтик, «Дебют» номинациясендә берьюлы ике актер җиңүче дип табылды. Алар – Тинчурин театрының «Хан кызы Турандык» спектаклендә Турандык роле өчен Әдилә Хәсәнова һәм Бөгелмә дәүләт театрының «Бездонное озеро» спектаклендәге Лева роле өчен Тимур Абдрахманов.

«Иң яхшы эпизодик роль»не исә Чаллы театры актрисасы Индира Маликова башкарган булып чыкты. Аңа бу премия «Хәл бу ки... Хәсән Туфан» (инсценировка авторы – Олег Кинҗәгулов) спектаклендә Клавдия роле өчен тапшырылды. Үзеннән тәҗрибәлерәк көндәш коллегаларын да уза алды яшь актриса.

«Икенче пландагы иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә Камал театрының «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» спектаклендәге Зөһрә әби ролен башкарган Алсу Гайнуллина җиңүче дип табылды. «Ничә яшендә булса да, актер өчен иң зур бүләк ул – спектакльдәге роль. Ә инде эшеңә менә шундый бәя һәм игътибар бирәләр икән, бу – бик күңелле хәл, әлбәттә», – диде актриса. «Икенче пландагы иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә исә Тинчурин театрының «Идегәй» спектаклендә Туктамыш хан ролен башкарган Ирек Хафизов җиңү яулады.

«Сезон дәвамында ирешкән уңышлар өчен» номинациясендә композитор Миләүшә Хәйруллина җиңүче булды. Ул язган «Кави-Сәрвәр» операсы «Иң яхшы музыкаль спектакль» була алмаса да, анда төп геройларны башкарган Эльза һәм Артур Исламовлар «Музыкаль спектакльдә иң яхшы роль (опера, музыкаль спектакль, мюзикл)» номинациясендә җиңде.

Иң яхшы актерларны барлауны дәвам иттереп, «Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясе җиңүчесен игълан иттеләр. Казанның Яшь тамашачы театры тәкъдим иткән «Здесь был Кай» спектаклендә Герда роле өчен Эльмира Рәшитова ул. «Иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә дә «Шварц, человек, тень» спектаклендә Шварц роле өчен шушы ук театр актеры Сергей Мосейога тиңнәр булмады. Ә «Намус һәм тугрылык» номинациясендә Минзәлә театры артисты Фоат Зариповны зурладылар.

Театраль сезонның иң яхшы спектакльләренә килгәндә, «Кече формадагы иң яхшы спектакль» һәм «Зур формадагы иң яхшы спектакль» номинацияләрендә Камал театрына тиңнәр табылмаган. Беренчесен Айдар Җаббаров куйган «Көл» спектакленә тапшырсалар, икенчесенә Айдарның остазы Фәрит Бикчәнтәев куйган «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» спектакле лаек булды. Сүз уңаеннан, соңгысы шактый гына номинациядә тәкъдим ителгән иде. Нәтиҗәдә камаллылар бу спектакль өчен ике премия белән кайтып китте.

Ихлас бүләкләр

Быелгы «Тантана»да махсус бүләкләр дә шактый булды. Аларны тапшырган мизгелләр аеруча ихлас булып истә калды. Хәтта ир затыннан булган җиңүчеләр күз яшьләрен тыя алмады. Әйтик, Бөтендөнья татар конгрессының махсус бүләген Әтнә театрының «Ак пароход» спектаклендәге малай роле өчен Рәзилә Шәрифуллина алды. Дамир Сираҗиев исемендәге премияне исә Түбән Кама театры актеры Юрий Павловка тапшырдылар. Моннан тыш, Татарстанның халык артисты Салават Фәтхетдинов быел да үзе булдырган Шамил Закиров исемендәге премия иясен котлады. Бу юлы премиягә Әлмәт театрында 30 ел электромонтер булып эшләгән Рөстәм Гыйлалов лаек булды.

– Быел Шамил Закировка 78 тулган булыр иде. Быелгы премиянең күләме дә – 78 мең, – диде Салават Фәтхетдинов. – Мин Камал театрыннан башка яши алмыйм, әмма бу елның иң яхшы спектаклен Әлмәт театры күрсәтте. «Ул әле өйләнмәгән иде» спектаклен иң яхшысы дип атар идем.

P.S. Шулай итеп, «Тантана»ның быелгысын да гөрләттеләр. Җиңүчеләргә премияләрен җыр һәм биюгә «төреп» тапшырдылар. Көтелмәгән җиңү һәм җиңелүләр булды, дия алмыйбыз. Татар дөньясын төрле мәгънәләрдә «шаулаткан» әсәрләр һәм артистлар премиягә лаек икән, «Тантана»га рәхмәтле булырга кирәктер.

«БУ ВАКЫТТА АКЫЛЛЫ СЫЕРЛАР ЙОКЛЫЙ...»

Соклану

Фирдиянең безнең авылда килен икәнен, районыбызның икенче почмагындагы Көшкәтбаш кызы булуын яшь буын белми дә. Хәер, безнең өчен дә күптән үз кеше, безнеке инде ул. Тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, берничә ел элек авылыбызга килен булып төшкән апаларында торып, Нормадагы СПТУда (ул безгә күпкә якын) бухгалтерлыкка укыды, аны тәмамлауга, унсигез яшендә инде авылдашыбыз Наилгә кияүгә чыкты.

Билгеле, кечкенә авылда бухгалтер белгечлеге буенча эш табылмый. Хәер, ул үзе дә эш талымлап, курып тормый. Башта бригадада төрле эшләрдә йөри, аннан икенче баласына өч ай булганда, фермага дуңгызлар карарга керә.

– Уйлап карасам, үзем дә шаккаттам, – ди ул бүген. – Каенанам Фәридә авариягә очрап, тернәкләнеп кенә килә, әле аягы гипста, ике таяк белән генә йөри, өч айлык Гөлинәмне аңа калдырып, эшкә чыктым бит. Эш арасында йөгереп кайтып имезәм... Ул елларда да фермага керәм дип торучы юк иде, даими эш урының булыр, диде өйдәгеләр. Олы кызыбыз Алинәне күрше авылдагы бакчага бирдек, аны әтисе йөртте...

Шул керүдән фермада егерме елга якын дуңгыз карый ул. Аның белән бергә эшләгәннәр ул чакта Фирдиянең бик тәвәккәл булуын, күмәк эштә дә башкаларга салынмавын, «батырып» эшләвен сокланып сөйлиләр иде. Бу тәвәккәллек тормыш иптәше Наилгә дә хас. Хуҗалыкта инженер-тәэминатчы булып эшләгән елларында Наил турында: «Барган җирдән беркайчан да буш кайтмый, нинди кытлык елларда да, ничек итсә итә, барыбер запчасть алып кайта», – дип сөйләгәннәре истә.

Өченче кызлары Зилияне алып кайткач, Вәлиевләр, тәвәккәлләп, КФХ оештыра, зур итеп абзар-кура коралар, күп терлек сатып алалар. Ит токымлы үгезләр симертү белән шөгыльләнә башлыйлар. Тик, кызганычка, алар шөгыльләнә башлагач кына, иткә бәяләр төшә, сорау ки-

ми... Зур өметләр белән тотынган эшләре уңышсызлыкка очрый... Ул елларда кичергәннәре... Башкасына түзә, әмма бурычлары өчен дип, абзарда басып торган соңгы сыерларын алып киткәндә, түзми Фирдия, сыерын кочаклап елый, алырга килүчеләрдән аны гына булса да калдыруларын ялварып сорый, тик рәхим-шәфкать кенә күренми... Бөтенесен нульдән, өр-яңадан башларга туры килә. «Ярый әле ул чакта авыл, район җитәкчеләре хәлебезгә керде», – ди алар бүген. Яшәп китәр өчен бу терәк бик вакытлы, урынлы була.

2017 елда авылыбызда дуңгыз фермасы ябылды, анда эшләүчеләрнең бик күбесе күрше Салавычка сыер саварга, терлек карарга күченде.

– Анда чыккач, моңа кадәр эшләп тилмергәнбез икән дидем, – дип искә ала Фирдия. – Дуңгыз фермасында бөтенесе кул хезмәте белән башкарыла иде бит: көн саен капчыкларга күпме он тутырабыз, читлекләр өстеннән йөреп, чиләк белән он, балык, бәрәңге ише өстәмәләр ташыйбыз, абзар себерәсе, юасы... Салавычка чыккач, башта элекке абзарда сыер саудым. Анда саву аппаратларын алып киләсе, соңыннан юасы була иде. 2020 елдан мегафермага күчтем. Монда инде бөтенесе автоматлашкан... Дөрес, Фирдия бик җайлы, җиңел генә дип сөйләгән мегафермага да эшләргә, сыер саварга килергә ашкынып торучы юк. «Күпләр төнге сменаны авырсына, – дип аңлата монысын Фирдия. – Бер ияләнгәч, мин кыенлыгын күрмим. Ничектер, төнлә тынычрак та эшләнә әле. Сыерларны гына шаярып тиргибез инде, бу вакытта бит акыллы сыер йокларга тиеш, ә сез 25әр литрга кадәр сөт бирәсез, дибез... »

1200 сыерны өч сменада дүртәр терлекче сава. «Сменадашларым бик әйбәт, килешеп, аңлашып эшлибез», – ди ул. Фермада эшләп кайттым дип, өйгә кайткач, ял итәргә ашыкмый Фирдия. «Яшь чакта күп бәйләдем. Аз гына буш вакыт булса, кулга бәйләү энәләре ала идем. Төпчек кызыбыз Зилиягә бер яшь тулган чакта 1300 сумга торт ясатып алдык. Шушы бәягә сатып алганчы, үзем пешереп карыйм әле дип тотынган идем... Башта туганнарга, таныш-белешләргә пешердем, хәзер инде даими клиентларым бар. Бераздан роллар белән кызыксынып киттем. Аларын интернеттан өйрәндем. Хәзер инде төрләре дә артты, сатып алучылар да... Заказлар кайчакта бик күп була, ничек тә өлгертергә тырышам. Мин аларны шулкадәр яратып эшлим, заказ булмаса, чабыш аты кебек борчыла башлыйм», – ди ул. «Теләгән кәсеп итәр, теләмәгән сәбәп эзләр» шушы буладыр инде...

Фирдияне якыннан белгәннәр андагы сабырлыкка да соклана. 50 яше тулмаган бу ханым кичергән югалту-сынауларны санап чыгар өчен генә дә шактый вакыт кирәк булыр иде. Әтиләренең үлемен бик тә авыр кичерә ул. Инде ул яра җөйләнә дигәндә, бер ел эчендә бертуган апасы Фәйрүзәне, әнисен, абыйсы Зөлфәтне югалта. Күп еллар начар авыру белән көрәшкән Фәйрүзәләре 50 яше тулган көнне күзләрен йомса, әнисе белән энесе, унике көн аерма белән, кинәт китеп бара. Югалтулар Наил ягында да күп була: аз гына аерма белән, әле йөгереп дөнья куар яшьтә әтисе, әнисе, 2018 елда, бөтен авылны хәсрәткә салып, 42 яшендә фаҗигале төстә энесе Айдар бакыйлыкка күчә. Ярты елдан инде Наилнең үзенә инфаркт була... Бу авырлыкларны алар бергә күтәрә, шул елларда ике кызларын укытып, кияүгә бирәләр, бүген ике онык сөяләр. «Ярый әле күп аерма белән төпчегебез Зилияне алып кайтканбыз. Шатлыгыбыз да, юанычыбыз да, булышчыбыз да ул безнең», – диләр.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5332 данә
Гомуми тираж – 15281 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 244

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+